**Татар телен өйрәнүдә УМК куллану.**

Баланы дөрес сөйләргә өйрәтү, аның сүз байлыгын арттыру, үз фикерен башкаларга ачык , аңлаешлы итеп сөйләргә өйрәтү балалар бакчасының төп бурычы булып тора.

Тел баланың барлык фән буенча белем алуына юл ача, фикер йөртү сәләтен үстерә һәм акыл үсешенә ярдәм итә. Ә телдәге кимчелек баланың акыл үсешен тоткарлый, фикер йөртүенә комачаулый, бала үз фикерен тулысынча сөйләп бирш  алмый. Дөрес сөйләргә өйрәнмәгән бала  дөрес итеп яза да алмый. Дөрес сөйли алмау баланың рухи халәтенә дә начар тэсир итә, ул кимсенә, боега, җавап бирүдән читләшергә тырыша, ятсына. Биш яшькә җиткән балаларның сөйләү органнары ана телендәге барлык авазларны да әйтергә сәләтле булып җитлегә. Авазларны әйтүдәге кимчелекләрне бетерү балалар бакчасыннан башланырга тиеш.

Без даими рәвештә шул юнәлештә эш алып барабыз. Безнең төркемдә барлыгы 23 бала. Шуларның бары унысы гына ана телен аңлый һәм сөйләшә ала.  Тугызы татар телен аңлый, ләкин татарча сөйләшә алмый, дүртесе бөтенләй аңламый . Безнең максатыбыз һәрбер баланың татарча сөйләшә алуына ирешү. Моның өчен УМК киң кулланыла, ягъни, без ана телендә мультфильмнар карыйбыз, хикәяләр, әкиятләр укыйбыз һәм балалар белән бергә эчтәлеген сөйләп карыйбыз,сюжетлы-рольле, хәрәкәтле һәм түгәрәк  уеннар уйныйбыз. Җырлар өйрәнәбез , шигырьләр ятлыйбыз. Картиналар буенча хикәяләр төзергә өйрәнәбез. Сәнгатьле сөйләм, кычкырып уку, хикәя төзеп сөйләу кебек эшләрне башкарганда  авазларны дөрес әйтү беренче урынга куела.

Белгәнебезчә, бала ана телендә камил сөйләшергә өйрәнсен өчен гаиләдә дә эшне дәвам итәргә кирәк. Шуңа күрә без әти-әниләр белән бергәләп эш алып барырга омтылабыз. УМК составына кергән мультфильмнарны өйдә карарга биреп җибәрәбез. Балалар бакчасында өйрәнгән шигырьләрне ныгыту өчен өйгә алырга тәкъдим итәбез. Бергәләп эшләсәк зуррак нәтиҗәләргә ирешербез дип ышанам.